СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Ямашурма, ул. Советская, 5

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯМАШИРМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ямаширмә авылы, Совет урамы, 5

Тел./факс: +7(84365) 3-29-74, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17 декабрь 2025ел** **№ 9**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында «2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карары нигезендә, Төзелеш министрлыгы тарафыннан раслануга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы архитектурасы һәм торак-коммуналь хуҗалыгы боерыгы 18.09.2025 № 1332/о «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Ямаширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге Советының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында», Ямаширмә авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге Советының аерым карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- 29.11.2018 ел, № 105 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»;
- 12.12.2012 ел, № 74 "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында".

2. Территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында белешмәләрне актуальләштерү өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына мәгълүмат җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф. К. Мохтаров